# ҺӘЙКӘЛ САЛГАН ӘДИП

Мамадыш янында бардыр
бер авыл, Тулбай, диләр.

Бөек Тукаебыз үскән Кырлай авылы белән аһәңдәш икән бит Шәйхи аганың туган авылы да. Берсен, менә, Тукай исеме бөтендөнья тарихына керткән һәм татар авылларының йөзек кашы иткән, Тулбайның да даны, беренче чиратта, Шәйхи Маннур исеме белән бәйледер ул.

Хәер, шундук сорау туа: без киләчәк өметебез, дип мәйданнарда, мөнбәрләрдә көткән яшь буын, мәктәп балалары Шәйхи Маннур һәм аның китапларының исемен яттан белә микән? Ул без генә, 50-60-70 нче елларда туганнар, Шәйхи Маннур, Нәби Дәүли, Зәки Нури, Габдрахман Әпсәләмов, Нури Арслан кебек фронтовик әдипләрнең әсәрләрен кырыпурып укый-укый үстек. Һич арттыру түгел, Г.Әпсәләмовның “Алтын Йолдыз” романында суасты корабында фашистлардан диңгез төбенә ятып качкан Урманов һәм Верещагиннарның язмышы өчен “Исән чыгарлармы, исән калырлармы?” дип дер-дер килә-килә янган-көйгән һәрбер мизгел истә. Нәби Дәүлинең “Җимерелгән бастион”ында, коры сөяккә калсалар да, Бөек Җиңү хакына чәнечкеле тимерчыбык артында түнтәрелеш-фетнә әзерләүче әсирләр һәм Шәйхи аганың тоткынлыктагы Җәлиле өчен дә бик аз кайгырмадык. Чөнки ул әсәрләр безнең буын өчен өстәл китаплары иде. Шулар безнең буынны иманлы һәм “без бетмәбез, тегеләр егылса да, без калырбыз”, дигән зур өметле итте. Ә 8 ел элек “милли компонентлар укытуны бетерергә, имтиханнарны урысча бирәсе булгач, балаларны Русия дәүләтенең бердәнбер телендә генә укытырга”, дигән 309 нчы танк-закон кергәч, аның чылбырлары мәктәп программаларындагы фронтовик әдипләрнең дә әсәрләрен сөреп-изеп чыкты. Әюгыйсә, чип-чиста “советча” булса да, Шәйхи аганың “Гайҗан бабай” поэмасындагы өзекләрне бүгенге буынга да ятлатмаслыкмыни? Йә, карагыз:

Гайҗан бабай сөйли,
һаман сөйли,
Чәе суына, аны сизми ул;
Куанычы эченә сыймаганга,
Һаман сөйли, һаман сөйли ул.

Менә шундый юллар укып үсәүсә, авылларыбызны һәм аларның күрке-горурлыгы булган геройларын яратып үстек бит без. Кендегебез күптән аерылса да, җаныбыз һәм рухыбыз белән туган-үскән нигезне сагынабыз. Шәйхи ага исә Тулбаенда үсеп чыккан да, кабат кайтып, шунда инде мәңгелеккә калган. Читкә китеп югалган һәм фани дөньяга ясинсыз күченгән миллионлаган татар туганнарыбыз, татар кардәшләребезгә караганда, валлаһи, бәхетлерәк!..

Гәрчә, аның тормыш юлын һич кенә дә җиңел, чокыр-сикәлтәсез, дип әйтеп булмый. Шәйхи Маннур (Шәйхелислам Фәрхулла улы Маннуров) 1905 елның 15 гыйнварында Мамадыш районының Тулбай авылында дөньяга килә. Туган авылында һәм күршедәге Шәмәк мәдрәсәсендә, Мамадыштагы педагогика курсларында белем ала. 1921 елда коточкыч ачлыктан һәм бер үк вакытта ЧОН отрядларының талавыннан качып, аның әтисе гаиләсе белән Кузбасска күчеп китә. Шәйхи Маннур да, әтисе белән иңгә-иң торып, Әнҗерә-Судженка шахталарында эшли башлый. Активлыгы белән танылгач, 1923 елда Свердловски каласындагы берьеллык партия-совет мәктәбендә чарлана. Шуннан соң өч ел буена Себернең төрле төбәкләрендә эшләп ала. 1927-1929 елларда армия сафларында хезмәт итә. Аннары Донбасска китеп, металлургия заводында – прокатчы, Днепрогэс төзелешендә - бетончы, хәтта “надан” (чөнки Мәскәүнең үзенә дә кирәкмәгән яңалифне белми) татар шахтерлары арасында мөгаллим булып та эшләп ала.

Әле Свердловски мәктәбендә укыган чагында ук Шәйхи Маннурның шигырьләре һәм әдәби язмалары әүвәл Уралда, аннары Казан белән Мәскәүдә яшәүче татарлар өчен чыгарыла торган гәзит-журнал битләрендә дөнья күрә башлый. “Тайга төбеннән” дип аталган беренче шигырьләр җыентыгы 1928 елда Казанда басыла. “Чиккән сөлге” (1928), “Елмаюлы кояш турында” (1929), “Чуен ташкыннары” (1931) исемле җыентыкларын инде Мәскәүдәге СССР халыкларының үзәк нәшрияты дөньяга чыгара. Шәйхи аганың “Колчеданлы таулар өстендә” (1929), “Чуен ташкыннары” (1930), “Бетончылар җыры” (1932) дип исемләнгән беренче поэмалары ук бөтен Советлар иле буйлап сибелеп яшәүче татар укучыларының игътибарын җәлеп итә. Беркадәр вакыт Мәскәүдәге “Эшче” гәзитендә дә эшләп каләм чарлагач, Шәйхи ага инде Казанга әйләнеп кайта, 1933-1937 елларда педагогика институтында белем ала. Каләмен ташламый, яңа китаплары һаман чыга тора.

Шулай да, Шәйхи Маннурны 1934 елда язылган “Гайҗан бабай” һәм бер елдан соң туган “Меңнән бер кичә” поэмалары дөньяга танытканд ыр. Бүгенге заман югарылыгыннан торып бизмәнгә салганда, әйтик, “Гайҗан бабай” поэмасының бик йомшак язылган шигъри мәкалә булып кына күренүе дә мөмкин. Ләкин онытмыйк: Такташ кебек кабатланмас даһины да “Такташ үлде” дигән шигырь язарга мәҗбүр иткән корыч кыршаулы, аждаһа заман бит бу. Ул еллар бөек Есенинны да совет Русен һәм аның Ленин-капитанын күкләргә чөеп мактарга мәҗбүр итә. Кара 30 нчы елларда түгел, хәтта 1957 елда да шул корыч кысалар Евтушенконы да Казан университеты белән бергә Ленинга һәм совет хакимиятенә мәдхия укырга мәҗбүр итте түгелме соң?

Ә Шәйхи аганың “хезмәт ударнигы” яки “труддень” дигән буш исемнәр өчен тир түккән Гайҗан бабае яки Такташның: “Элек чакта мин бер кеше идем, хәзер, малай, миндә ике “мин”, берсе менә аның коммун яклы, икенчесе каршы, суккин сын!” - дип сыкраучы Мохтар карты турында бүгенге



мәктәп балаларына да укытасы иде. “Колчедан чыгарыйк, чуен койыйк”, - дия-дия җан атып һәм кара тиргә батып, бер тиен түләүсез килеш Магнитка заводларын, Днепрогэсларны, Донбассны төзеп куйган бабаларыбыз батырлыгы, туган илгә мәхәббәте, сабыйларча самимилеге турында да укытасы иде. Ә нигәме? Безнең әнә шул, кара тиргә батып бабаларыбыз бушка төзегән колхозларны, ГЭСларны, заводларны бүгенге казна караклары кесәләренә бөтереп салды бит. Шәйхи ага, Такташ шигырьләре тарихны искә төшерү, күзне ачып, җәмгыятькә аек карау, бүген кемнәр кесәсе хакына бил бөгүеңне, ахыр чиктә күрше дәүләттә нинди дәһшәтле янгын дөрләвен аңлау өчен һаман-һаман кирәк икән, димәк. Әдәбият берчакта да искерми, тик юллар арасыннан хакыйкатьне, ачы сабакларны эзләп табасы бар...

Шәйхи агага яки Шолоховка “колхоз сандугачы, совет колы” дигән мөһерләрне сугарга ашыкмыйк без. Авылдашларыңның, күршеләрнең соңгы сарыкларынбәрәннәрен совет активистлары күмәк абзарга талап киткән чакта аларның үкереп-үкереп елап калуын карап тору өчен таш йөрәкле, йә бөтенләй бәгырьсез булу кирәк. Шәйхи ага – әтисенең атын җигеп, әнисе сауган җылы сөттән ләззәт алып үскән авыл малае ул. Аның да, Сталин комиссарларының вәхшилеген, җәлладлыгын күреп, йөрәгенә күпме кан саугандыр! Ә ул яшүсмер чакта төзелгән колхозларның соңыннан бер карак кесәсенә кереп утырачагын күрәзәлек итә алган булса, күпме елар-сыктар иде икән әле тагын?!

Шәйхи ага, совет төзелешләренә һәм колхоздагы самими хезмәт батырларына дан җырлаган өчен, 1939 елда Хезмәт Кызыл Байрагы орденына лаек була. Андый кавалерларны, хәтта түгелләрен дә, Бөек Ватан сугышы башлангач, эшелоннарга утыртып, Мәскәүдән безнең Чистайга ял һәм иҗат итәргә китереп тутырганнар. Нәкъ аларга каршы юнәлештә, берберсенә эчкерсез һәм беркатлы кул болгашып, безнең Абдулла Алиш, Муса Җәлил, Фатих Кәрим, Гадел Кутуй кебек әдипләребез, Фәрит Яруллин шикелле талантлы татар моңчылары зур Ватанны, өстәвенә әле Чистайдагы каләмдәшләренең иминлеген дә сакларга дип, дары-кан эченә, фронтка чыгып киткән. Бик теләгән, хәйлә корган булса, Шәйхи ага да, тегеләр шикелле, тылда, алар янәшәсендә кала алган булыр иде. Теләмәгән, башкалар җилкәсе артына качып калуны кешелеге, җаны күтәрмәгән. Ул иңенә Җәлилләр, Кутуйлар йөген салып киткән булган. Тәкъдир дус-каләмдәшләренә караганда миһербанлырак итеп елмайса да, канлы сугышның башыннан ахырынача фронт гәзитләрендә эшләгән, дистәләгән тапкыр үлем белән йөзгә-йөз очрашкан, урыс баһадирлары белән рәттән татар яугирләренең каһарманлыгын да тарихларга чиккән.

Онытмыйк: Шәйхи ага – Муса Җәлилне әле 30 нчы еллар уртасыннан, Мәскәүдә чагында ук күреп белгән кеше. Гәзитләрдә бергә эшләгәннәр, Казанда чагында, бергәләшеп, “Васильево” санаториенда ял иткәннәр, әдәби утырыш яки җыелышларда, бәхәсләшә-бәхәсләшә, уртак тел тапканнар. Шәйхи ага өчен Муса газиз булган, моңа шик юк. Бөек Ватан сугышыннан соң Җәлил өстенә түгелгән яманатларны да, аның гаиләсе кичкән михнәтләрне дә үз йөрәге аша үткәргәндер. Әнә шул яманатларны тизрәк кырып төшерү, газиз каләмдәшен һәм чордашын милләт тарихына алтын җепләр белән чигү өчен 1959 елда ук “Муса” дигән тарихи романын язуга алынган бит.

Шәйхи ага бу романны 1964 елда язып тәмамлаган. Тулбайдагы музей-китапханәсендә аның тәүге корректурасын, бик сак кына итеп, актарган, укыган бар. Хөкүмәтнең бәйдәге ялчылары булган цензорлар бу әсәрне битебите генә түгел, бүлеге-бүлеге белән кискәләп һәм турап талаган. Нәтиҗәдә “Муса” романы 1968 елда гына дөнья күрә алган, аны әле 7 елдан соң, кабат та бастырып чыгарганнар.

Бүгенге мәгълүмат арсеналы белән Шәйхи ага әсәренә “Муса алай түгел, болай һәлак булган; автор тарихи вакыйгаларны ачыклап бетермәгән көе шундый зур хезмәткә алынган”, дип мөһер сугарга да буладыр. Ләкин хәтер казанын, иң элек, үзебез кырып карыйк. Каһарман Кормаш-Җәлилчеләрнең гильотинада җәзалап үтерелүе турындагы архив мәгълүматлары безнең илгә 60 нчы еллар ахырында гына кайтып җитә. Хәтта Җәлилнең 50 еллык юбилеен да Казан университетының актлар залында, киң җәмәгатьчелек күзеннән качып үткәрәләр. 60 еллык юбилее гына Татар дәүләт опера һәм балет театрына һәм Мәскәү залларына үтеп керә ала. Ә Шәйхи ага, “Тулбай карты” җәлилчеләрне әле 1959 елда ук ил өстенә күтәреп чыгара башлады бит! Һәм, кабат-кабат, кем алдында бурычлы булуыбызны искә алыйк. Җәлилнең беренче “Моабит дәфтәре”н 1946 елда Нигъмәт Терегулов атлы әсир-каһарманыбыз Казанга кайтарып җиткергән, аның үзен өч тәүлек үтүгә кулга алып, Черек күл зинданында атып үтергәннәр. Әгәр икенче дәфтәр Бельгиядәге көрәштәше Андре Тиммерманс тырышлыгы белән кайтып ирешмәсә, безнең “җәлилчеләр” атлы милли горурлыгыбыз да булмас, аларның исеме хыянәтчеләр сафыннан чыга да алмас иде...

Шәйхи аганы әүлия дә, фәрештә дә, димим. Бер генә адәм баласы да ялгышу һәм абынулардан хали була алмый. Заманасы җиңел, күге азат түгел. Гел Мәскәү ягына карап атласаң, чокырга төшеп егылу да бик үк ерак йөрмәс. Ә гапгади Тулбай егете булган Шәйхи ага, йә мәрхәбә, татар икенче сортлы халык хәлендә изелгән һәм хөкүмәт аның мәктәпләрен япкан, телен тартып алырга маташкан чираттагы погром заманында да газиз милләтенең кайнар каны һәм рупоры булып, шүрләмичә, күкрәп яши алган! Аның 1957 елда СССР җитәкчесе Никита Хрущевка язган хатын гына укып карагыз сез. Без хәтта 1991 елда да Татарстанга союздаш республика статусы бирүләрен даулап, даладагы чыра төсле яндык. Ә “Тулбай карты” бездән 35 елга алдарак уянган бит!

Шәйхи аганың тагын бер изгелеге алдында мәңге баш иярлек.

